**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 5 июнь № 416

г. Казань

Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карага теркәлгән Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибен һәм шартларын расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\416.doc

Татарстан Республикасы
Министлар Кабинетының
2015 ел, 5 июнь, 416 нчы
карары белән расланды

# Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру тәртибе һәм шартлары

1. Әлеге Тәртип Төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә расланган объектларны (алга таба – объектлар) дәүләт милкендә яки муниципаль милектә булган җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә (алга таба – җир кишәрлекләре), җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру процедураларын һәм шартларын регламентлаштыра.

Әлеге Тәртип «Реклама турында» 2006 ел, 13 март, ФЗ-38 нче Федераль закон нигезендә урнаштырылуы гамәлгә ашырылган тышкы реклама чаралары булган төзекләндерү объектларын урнаштыруга таралмый.

2. Объектларны җир кишәрлекләрендә, җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар билгеләмичә урнаштыру (алга таба – объектларны урнаштыру), объектларны урнаштыру Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, 540 нчы боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторы нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төренә ярашлы рәвештә җир кишәрлекләрен куллана алмау мөмкинлегенә китерми дигән шарт белән, нинди дә булса хокукта гражданнарга яки юридик затларга бирелмәгән җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә гамәлгә ашырыла.

3. Объектларны урнаштыру Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, яисә муниципаль милектә булган яки дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләрен бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы рөхсәте нигезендә тормышка ашырыла.

4. Объектларны урнаштыру түләүле гамәлгә ашырыла. Түбәндәге объектлар чыгарма булып торалар:

территорияне төзекләндерү элементлары;

мәгълүмат такталарын (стелаларны) һәм флагштокларны кертеп, геодезия, межалау, кисәтү билгеләре һәм башка билгеләр;

урнаштыру өчен төзү рөхсәте кирәк булмаган саклаучы корылмалар;

урнаштыру өчен төзү рөхсәте кирәк булмаган үтү юллары, шул исәптән трасса буйлап, һәм керү юллары;

янгын сулыклары һәм янгын сүндерү чараларын туплау урыннары;

парга әйләндерү өчен буалар;

35 кВ кадәр көчәнеш классы булган электр тапшыру линияләре, шулай ук алар белән бәйле трансформатор ярдәмче станцияләре, бүлү пунктлары һәм урнаштыру өчен төзү рөхсәте кирәк булмаган электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыручы башка җайланмалар.

5. Объектларны урнаштыру өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$ПР \quad \frac{Рап \ x \ Пзу}{12} \ x \ N,$$

монда:

*ПР* – объектларны урнаштыру өчен түләү күләме, сум;

*Рап* – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары нигезендә исәпләнгән еллык аренда түләве күләме, кв.метр өчен сум;

*Пзу* – объектлар урнаштырыла торган мәйдан, кв.метр;

*N* – объектлар урнаштырыла торган айлар саны.

6. Объектларны урнаштыруга рөхсәтнамәдә, бөтен җир кишәрлеген куллану планлаштырылган очракта, җир кишәрлегенең кадастр саны, яисә җир кишәрлегенең өлешен куллану планлаштырылган очракта, җир кишәрлекләрен урнаштыруның күздә тотылган урыны күрсәтелә.

7. Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирү турында гариза (алга таба – гариза) физик яки юридик зат, шәхси эшмәкәр (алга таба – гариза бирүче) яисә гариза бирүченең вәкиле тарафыннан вәкаләтле органга бирелә.

8. Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

а) гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) әтисенең исеме һәм аның шәхесен таныклаучы документның реквизитлары – гариза физик зат тарафыннан бирелгән очракта;

б) гариза бирүченең исеме, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы һәм Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турында белешмәләре – гариза юридик зат тарафыннан бирелгән очракта;

в) гариза бирүченең урнашу урыны һәм Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турында белешмәләре – гариза шәхси эшмәкәр тарафыннан бирелгән очракта;

г) гариза бирүче вәкиленең фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) әтисенең исеме һәм аның вәкаләтләрен раслаучы документның реквизитлары – гариза гариза бирүче вәкиле тарафыннан бирелгән очракта;

д) гариза бирүче яки гариза бирүче вәкиле белән элемтәгә керү өчен почта адресы, электрон почта адресы, телефон номеры;

е) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә расланган исемлеккә ярашлы рәвештә объектларның күздә тотылган төре;

ж) объектларны урнаштыруның күздә тотылган урыны, аларны планлаштырылган җир кишәрлегендә урнаштыруның нигезләмәсе, шулай ук объектларны урнаштыру өчен кирәкле җир кишәрлеге мәйданының якынча күләме;

з) урнаштырыла торган объектлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән саклау, санитария-саклау зонасы, башка зона (алга таба – җирләрне куллануның махсус шартлары булган зоналар) билгеләү кирәклеге;

и) җир кишәрлегенең кадастр саны – бөтен җир кишәрлеген куллану планлаштырылган очракта, яки территория чикләренең характерлы нокталары координатлары – җирләрне яки җир кишәрлегенең өлешен куллану планлаштырылган очракта;

к) җир кишәрлегеннән файдалану вакыты.

9. Объектның урынын һәм аның чиктәш җир кишәрлекләренең урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирүче объектларның җир кишәрлегендә урнашу схемасы (1:500 масштабында ситуация планы, адресы), гариза бирүченең һәм гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклаучы документларның күчермәләре һәм, гариза гариза бирүченең вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, гариза бирүче вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе гаризага теркәлә.

10. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә ала:

а) җир кишәрлеге турында кадастрдан өземтә яки җир кишәрлегенең кадастр паспорты;

б) Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

в) муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектларны урнаштыруга ризалыгы – объектны урнаштыру Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашырылган очракта;

г) объектларны урнаштыру проектының техник-икътисадый нигезләмәсе яки кирәкле исәп-хисаплар;

д) объектларны планлаштырылган җир кишәрлегендә урнаштыру кирәклеген раслаучы башка документлар.

11. Гариза бирүче әлеге Тәртипнең 10 нчы пунктындагы а – в пунктчаларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, әлеге документлар вәкаләтле орган тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына.

12. Объектларны урнаштыруга яки рөхсәт бирүдән баш тарту турында рөхсәтнамә вәкаләтле орган тарафыннан гаризаны алганнан соң, 10 эш көне эчендә һәм әлеге карарны кабул иткән көннән соң, 3 эш көне эчендә гариза бирүчегә, ул тапшырган документларны теркәп, заказлы хат белән юллана.

13. Объектларны урнаштыруга рөхсәтнамә үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

а) җирләрне яки җир кишәрлекләрен куллану әлеге җирләр һәм җир кишәрлекләре чикләрендәге туфракның уңдырышлылыгын бозуга яисә бетерүгә китергән очракта, объектларны урнаштыруга рөхсәтнамә алган затларның Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы белән күздә тотылган таләпләрне үтәү бурычлары турында күрсәтмә;

б) объектларны урнаштыру өчен түләү күләме – объектларның күздә тотылган төрен урнаштыру максатларында җир кишәрлеген куллану түләүле гамәлгә ашырылган очракта;

в) җир кишәрлегеннән файдалану вакыты;

г) объектларны урнаштыруга рөхсәтнамә алган затларның җирләрне куллануның махсус шартлары булган зона чикләре урнашкан урын тасвирламасын, аны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләү кирәк булган очракта якынча тапшыру вакыты;

д) объектларны урнаштыруга рөхсәтнамәне урнаштыру рөхсәт ителгән объектлар белән һәм әлеге урнаштыру рөхсәт ителгән урын белән (җир кишәрлеге, җир кишәрлеге өлеше) чагыштырырга мөмкинлек бирүче белешмәләр.

14. Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тарту түбәндәге очракларда кабул ителә:

а) гариза әлеге Тәртипнең 8, 9 нчы пунктлары белән билгеләнгән таләпләрне бозып бирелгән булса;

б) гаризада Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясындагы 3 нче пункт нигезендә расланган объектлар төрләре исемлегенә керми торган күздә тотылган объектлар төрләре күрсәтелгән булса;

в) объектларны урнаштыру өчен планлаштырылган җир кишәрлеге Татарстан Республикасы милкендә, муниципаль милектә булмаса, дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләренә кермәсә;

г) планлаштырылган җир кишәрлеге гражданнарга яки юридик затларга бирелгән булса;

д) объектларны планлаштырылган җир кишәрлегендә урнаштыру Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторын раслау турында» 2014 ел, 1 сентябрь, 540 нчы боерыгы белән расланган Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән куллану төрләренең классификаторы нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән куллану төренә ярашлы рәвештә җир кишәрлекләрен куллана алмау мөмкинлегенә китерсә.

15. Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуда әлеге Тәртипнең 14 нче пункты белән күздә тотылган баш тартуның нигезе күрсәтелгән булырга тиеш.

Гариза әлеге Тәртипнең 8, 9 нчы пунктлары белән күздә тотылган таләпләрне бозып бирелгән булса, объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуда әлеге бозу нәрсәдән гыйбарәт булганы күрсәтелергә тиеш.

16. Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләү кирәк булган очракта, җирләрне куллануның махсус шартлары булган зона чикләре урнашкан урын тасвирламасы Гариза бирүче тарафыннан объектларны урнаштыруны тәмалаганнан көннән соң, 30 көн эчендә әзерләнә һәм, территория зонасы яки территорияләрне куллануның махсус шартлары булган зона чикләренең характерлы нокталары координатларының исемлеге рәвешендә, күчемсез мөлкәткә дәүләт кадастрын алып бару өчен билгеләнгән координатларны координатлар системасында билгеләү ысулын һәм җитешсезлеген күрсәтеп, вәкаләтле органга тапшырыла.

Гариза бирүче җирләрне куллануның махсус шартлары булган зона чикләре урнашкан урын тасвирламасын объектларны урнаштыруга рөхсәтнамә белән билгеләнгән вакытта бирмәгән очракта, вәкаләтле органга куллануның махсус шартлары булган зона чикләре урнашкан урын тасвирламасын тапшыру вакытын озайту турында үтенеч язуы юллый.

17. Куллануның махсус шартлары булган зона чикләре урнашкан урын тасвирламасын алган көннән соң, 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган әлеге тасвирламаны «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына җибәрә.

18. Объектлар урнаштырылган җир кишәрлеге нинди дә булса хокукта гражданнарга яки юридик затларга бирелгән булса, вәкаләтле орган җир кишәрлеген бирү турында карар кабул иткән көннән соң, 10 эш көне эчендә Гариза бирүчегә җир кишәрлегенең әлеге затларга бирелүе турында белдермә юллый. Бу очракта объектларны урнаштыруга рөхсәтнамәнең көче саклана.

19. Объектларны гражданнарга һәм юридик затларга бирелмәгән яисә дәүләт предприятиеләренә яки дәүләт учреждениеләренә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнаштыруга рөхсәт бирү Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы тарафыннан кабул ителгән булса, объектларны урнаштыру өчен түләү Татарстан Республикасы бюджетына кертелә, килә һәм күчерелә.

Объектларны гражданнарга һәм юридик затларга бирелмәгән яисә муниципаль предприятиеләргә яки муниципаль учреждениеләргә бирелгән җир кишәрлекләрендә урнаштыруга рөхсәт бирү дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләрен бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән булса, объектларны урнаштыру өчен түләү тиешле муниципаль берәмлек бюджетына кертелә, килә һәм күчерелә.

Объектлар урнаштырылган җир кишәрлеге, объектларны урнаштыруга рөхсәт бирү кабул ителгәннән соң, гражданнарга һәм юридик затларга бирелгән булса, объектларны урнаштыру өчен түләү җирдән файдаланучыга, җир хуҗасына, җир кишәрлеген арендага алучыга күчерелә, дәүләт предприятиеләреннән, муниципаль предприятиеләрдән яки дәүләт учреждениеләреннән, муниципаль учреждениеләрдән тыш.

20. Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләренә мөнәсәбәттә милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы яисә дәүләт милке чикләре билгеләнмәгән җир кишәрлекләрен бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы белән төзелгән ведомствоара комиссиядә гариза бирүче тарафыннан объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуга шикаять бирелә ала

Объектларны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартуга шикаять шулай ук Гариза бирүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә бирелә ала.